Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

«12» февраль 2019 ел № 114

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августагы 61 номерлы карары белән расланган " Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмә"гә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге Советы гамәлдәге законнарга туры китерү максатында карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 61 номерлы карары белән расланган Кече Салтык авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партия" сүзләреннән соң "билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче ур., 9 нчы йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9 нче йорт, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кече Салтык
авыл җирлеге Советы рәисе А.Г.Җиһаншин